Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Советының унөченче утырышы

Надеждино авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

31 март, 2022 ел № 38

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү эшен оештыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Шәһәр һәм авыл җирлекләре территорияләрен карап тотуга, су объектларына, эчәргә яраклы суга һәм эчәргә яраклы су белән тәэмин итүгә, атмосфера һавасына, туфракка, торак биналарга, җитештерү, җәмәгать биналарын эксплуатацияләүгә, санитария-эпидемияләргә каршы (профилактика) чаралар үткәрүгә карата санитар-эпидемиологик таләпләр» СанПин 2.1.3684-21 инструкциясенә, Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге уставына нигезләнеп **Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты карата карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы « Надеждино авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү эшен оештыру турында Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Советының 2016 елның 27 сентябрендәге 39 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- Нигезләмәнең преамбуласында «СаНПиН 2.1.2882-11» сүзләрен «СанПиН 2.1.3684-21» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов